Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл башкарма комитеты

# КАРАР

4 август 2023 ел № 6

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешсез урында җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 30 июнендәге 02-08-02/766 номерлы күрсәтмәсен карап

Колшәрип авыл башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешсез урында җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Кагыйдәнең 4 пункты нигезендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыннарын билгеләргә, шул исәптән, күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмаганга туплау мөмкин булмаган очракларда, шулай ук кулланучыларга мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат бирергә.

2. Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Колшәрип авыл җирлеге, Колшәрип авылы Тукай ур. 50 йорт адресы буенча кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыны итеп махсус тартма билгеләргә.

3. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл башкарма комитетының «Колшәрип авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны беренчел җыюны һәм урнаштыруны оештыру турында» 2016 елның 27 октябрендәге 10 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Колшәрип
авыл башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Кәшәфетдинов